**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында судагы биологик ресурсларны саклау мәсьәләләре буенча республика советы составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында судагы биологик ресурсларны саклау мәсьәләләре буенча республика советы турында» 2016 елның 4 ноябрендәге ПУ-985 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 12 декабрендәге ПУ-1090 номерлы, 2017 елның 20 октябрендәге ПУ-915 номерлы, 2018 елның 14 маендагы ПУ-370 номерлы, 2019 елның 19 мартындагы ПУ-174 номерлы, 2019 елның 11 июлендәге ПУ-396 номерлы, 2020 елның 18 апрелендәге ПУ-240 номерлы, 2020 елның 12 августындагы ПУ-482 номерлы, 2021 елның 5 октябрендәге ПУ-792 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 14 апрелендәге 234 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында судагы биологик ресурсларны саклау мәсьәләләре буенча республика советы (алга таба – Совет) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Совет составыннан М.А. Шинкаревны чыгарырга;

б) Совет составына Гуляев Александр Мартиковичны – Балыкчылык буенча федераль агентлыкның Идел-Кама территориаль идарәсе җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы буенча судагы биологик ресурсларга дәүләт контроле, күзәтчелек һәм аларны саклау бүлеге башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручыны кертергә (килешү буенча);

в) Совет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

А.В. Артемьевның – «Су ресурслары федераль агентлыгы Түбән Идел су бассейны идарәсенең Татарстан Республикасы буенча су ресурслары бүлеге башлыгы (килешү буенча)»;

Л.Н. Гарипованың – «Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2023 ел, 01 сентябрь
№ 612